КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 26 июль г.Казань № 888

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 ел, 19 май, 612 нче карары белән расланган Дәүләт (муниципаль) учреждениеләре булмаган юридик затларга һәм индивидуаль эшкуарларга Татарстан Республикасы территориясендә туристлык инфраструктурасын үстерүгә юнәлдерелгән инициативаларны гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарының бер өлешен финанс белән тәэмин итү максатларында Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Дәүләт (муниципаль) учреждениеләре булмаган юридик затларга һәм индивидуаль эшкуарларга Татарстан Республикасы территориясендә туристлык инфраструктурасын үстерүгә юнәлдерелгән инициативаларны гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарының бер өлешен финанс белән тәэмин итү максатларында Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2023 ел, 19 май, 612 нче карары белән расланган Дәүләт (муниципаль) учреждениеләре булмаган юридик затларга һәм индивидуаль эшкуарларга Татарстан Республикасы территориясендә туристлык инфраструктурасын үстерүгә юнәлдерелгән инициативаларны гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарының бер өлешен финанс белән тәэмин итү максатларында Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

11 пунктта:

җиденче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«белешмә формалашкан датага аның урнашкан урыны буенча, әмма конкурс уздыру планлаштырылган айдан алдагы айның 1 числосыннан да иртәрәк түгел конкурста катнашучыны аның урнашкан урыны буенча салым органында исәпкә кую урыны буенча салым органы тарафыннан бирелгән салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә конкурста катнашучы тарафыннан салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү бурычларының үтәлеше турында белешмәләр (конкурста катнашучы мондый документны тапшырмаган очракта, вәкаләтле орган аны ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек тәртибендә мөстәкыйль рәвештә соратып ала);»;

сигезенче абзац үз көчен югалткан дип танырга;

унынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтендә тиешле рәвештә теркәлгән, проектны субсидияләр акчалары исәбеннән гамәлгә ашыру күздә тотыла торган җир кишәрлегенә хокукны раслый торган хокук билгели торган документларның күчермәләре, җир кишәрлеге урнашкан җирләрнең категориясе һәм җир кишәрлегеннән рөхсәт ителгән файдалану рәвеше турында белешмәләр дә кертеп, җир кишәрлегенә күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрыннан милек хокукын яисә җир кишәрлегенә субсидияләр алучының арендалау/субарендалау хокукын раслый торган өземтә, я җир кишәрлекләре бирмичә объектлар урнаштыруга һәм сервитутлар билгеләүгә рөхсәт күчермәсен, ә җир кишәрлеге җирләр категориясенә һәм бирелгән җир кишәрлегеннән рөхсәт ителгән файдалану төренең эшчәнлекнең проект белән каралган төренә туры килмәгән очракта - субсидияне законнарда билгеләнгән тәртиптә алган көннән соң беренче айдан да соңга калмыйча җир категориясен һәм (яисә) җир кишәрлегеннән рөхсәт ителгән файдалану төрен проект тарафыннан каралган эшчәнлекнең тиешле төренә үзгәртүгә гариза белән мөрәҗәгать итү турында гарантияле хат;».

2. Әлеге карарның 1 нче пункты гамәле 2023 елның 24 маеннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин